# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

17 08 2026 ел Яр Чаллы ш. №2798

«Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 06 октябрендәге 3012 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «Мәгълүмати элмә такта урнаштыру, элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 06 октябрендәге 3012 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.3.2.1 пункты 11 нче абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү орган (оешма) билгеләнгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче запросның электрон формасында һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал запросның электрон формасында дөрес тутырылмаган кырны ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү мәсьәләләре буенча урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов